ПРОЕКТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 елның «___» маеннан № ____

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында өч һәм аннан күбрәк савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга саву аппаратын сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 28 апрелендәге 203 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2025 елның 20 маендагы 339 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 09 апрелендәге 378 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында өч һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 28 апрелендәге 203 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 31 августындагы 354 номерлы, 2021 елның 08 декабрендәге 492 номерлы, 2022 елның 14 апрелендәге 120 номерлы, 2022 елның 18 октябрендәге 300 номерлы, 2023 елның 11 апрелендәге 109 номерлы, 2023 елның 13 сентябрендәге 201 номерлы, 2024 елның 15 гыйнварындагы 6 номерлы карарларындагы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.6 пунктының икенче абзацында «шәхси» сүзен төшереп калдырырга;

3.3 пунктта «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан бирелгән субсидияләр» сүзләрен «Субсидия акчалары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов